**СОВЕТ ПЕЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422612 с. Пелево,
ул. Советская , д. 9
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПӘРӘҮ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422612 Пәрәү авылы,
Совет урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

---

**2024 елның 30мае** **13 номер**

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023елның 23 ноябрендәге 24 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 79 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 23 мартындагы 54-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 28.1 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге советының 2023 елның 23 ноябрендәге 24 номерлы карары (2024 елның 01 февралендәге 1 номерлы соңгы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1) 14 нче бүлекнең 1 нче өлешен түбәндәге эчтәлектәге 13 нче пункт белән тулыландырырга:

«13) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетада аңа билгеле булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба – анкетада булган мәгълүматлар).»;

2) 15 нче бүлекнең 1 нче өлешендәге 8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган

чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

3) 3 нче бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 21.1 бүлеге белән тулыландырырга:

«21.1. Анкетаны тәкъдим итү, анкетада булган мәгълүматны үзгәртү турында хәбәр итү һәм мондый мәгълүматны тикшерү»

1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тәкъдим итә.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкета формасы, шул исәптән анда кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетада булган мәгълүматлар яллаучы (эш бирүче) вәкиле яки аның вәкаләтлесе карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, запрослар җибәрү юлы белән башкарыла. Тиешле мәгълүматка ия булган җәмәгать хакимияте органнары һәм оешмалары соралган мәгълүматны әлеге сорауны алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

4) 22 нче бүлектә:

а) 3 нче өлешнең 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетаны»";

б) 4 нче өлешне "мәгълүмат" сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)»сүзләре белән тулыландырырга;

5) 38 нче бүлектә:

а) 11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыруны һәм үткәрүне;»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункт белән тулыландырырга:

«11.1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү;»;

6) 39 нчы бүлекнең 4 нче өлешендә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) максатчан укыту турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия.».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Пәрәү
авыл җирлеге Советы рәисе** **Ф.Ф. Тимергалиев**